ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ШУГУРОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ШӨГЕР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2022 елның 31 октябре Шөгер №48

Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлеге Шөгер торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлеге Шөгер торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2022 елның 19 ноябренә 10 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлеге Шөгер торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2022 елның 19 ноябренә 12 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

3. Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлеге Шөгер торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2022 елның 19 ноябренә 14 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

4. Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлеге Шөгер торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2022 елның 19 ноябренә 16 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

5. Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең Шөгер торак пунктында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билгеләр буенча гражданнар җыенын уздыру өчен бүлү тәртибен билгеләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Шөгер авыл җирлеге Шөгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, 4 һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

- Авыл җирлеге чикләрендә юлларны карап тоту
- Урам яктыртуын оештыру
- Җирлек территориясен төзекләндерүне һәм яшелләндерүне оештыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Киров ур., 17, балалар бакчасы, Киров ур., 23, «ЛТС» ҖЧҖ - Ленин ур., 32, Шөгер авыл мәдәният йорты, Ленин ур., 35, Шөгер 3 участок хастаханәсе, Горький ур., 4 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында (leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга..

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Н.Гафиятуллин